Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение гимназия с. Раевский

| СОГЛАСОВАНО | РАССМОТРЕНО | УТВЕРЖДАЮ |
|---|---|---|
| на заседании ШМО учителей башкирского языка и татарского языка<br>Протокол №1<br>от «26» августа 2016г. | на заседании научно - методического совета<br>Протокол №1<br>от «29» августа 2016г. | Директор МБОУ гимназия с. Раевский<br>________________Колеганов С. Н.<br>Приказ №<br>от «29» августа 2016г. |

# Рабочая программа

## по родному языку

## в 5В классе

Срок реализации: 2016 -2017 учебный год

Составитель: учитель татарского языка и литературы Насырова Л.М.

Составлено на основе программы по татарскому языку

2016год

# ЭЧТӘЛЕК

I. Аңлатма язуы.
II. Укыту предметына гомуми аңлатма.
III. Укыту предметының укыту планында тоткан урыны.
IV. Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре.
V. Укыту предметының төп эчтәлеге.
VI. Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча  планлаштырылган нәтиҗәләре.
VII. Укыту предметының темаларга якынча бүленеше.
VIII. Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү.

# Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон  Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Башкортостан Республикасы Законы.
3. Гомуми белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы
4. ”Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары. 1-11 нче сыйныфлар”. – К., ,,Мәгариф” нәшрияты, 2010, 128б.
5. Раевка авылы гимназиясенең  2016-2017 нчы уку елына расланган укыту планы
6. Дәреслек: Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 5 нче сыйныфы өчен дәреслек ( татар балары өчен)/ Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисов.- Казан: Мәгариф, 2004. – 174б.

Эш программасы тел һәм әдәбият темаларын берләштерелеп төзелде, чөнки дәрес  2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планында  “Туган тел” буларак бирелә.

## Укыту предметына гомуми аңлатма.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш". Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Татар теле укытуның максатлары:

- Укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;
- Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә иректе куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;
- Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрләләндерү;
- Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.

### Татар теле укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларның логик фикеләү сәләтләрен үстерү.
6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Укыту планында 5 нче сыйныфта татар теленнән атнага 1 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик планны “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен): 1-11 сыйныфлар.”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010.) нигезләнеп төзедем. Программада 34 сәгать каралган.

## УКЫТУНЫҢ ГОМУМИ, ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Төп һәм (урта)гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларында татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– Укучыларның коммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашукүнекмәләре булдыру;
– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
– “Татар теле һәм әдәбияты” фәненәкарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыруһәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

### Укытуның шәхси нәтиҗәләре

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларын тәгәлләгәндә,укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

– шәхесара һәм мәдәният ара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”,төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

### Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

Төп һәм(урта) белем бирү баскычларындататар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (*танып-белү, регулятив, коммуникатив)*формалаштыругахезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алукүнекмәләре формалаша.

*Танып-белүнәтиҗәләре:*

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

*Регулятив нәтиҗәләр*:

– уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

*Коммуникатив*нәтиҗәләр:

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисле лек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү

## Укыту предметының төп эчтәлеге

*Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:*

- ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;
- телдән һәм язма сыйләм, диалог, монолог, аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә (радио, телеведениедән һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктацион)саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- ана теленең грамматик категорияләрен белү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сүз, сүзтезмә, җөмләләрдәге хаталарны төзәтү;
- җөмләгә синтаксик анализ ясау;
- төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача, гади һәм кушма җөмләләр кулланып сөйли белү;

- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, сурәтләү яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерлзү;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- төрмыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу
- текстның планын төзү ;
- тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;
- ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре | | | |
| 1 | Башлангыч сыйныфларда алган белемнәрне кабатлау | 1 | Регулятив УУЭ: план буенча эшләргә өйрәнү, үз эшмәкәрлегеңне дәреснең максаты белән чагыштыра белү, үз-үзеңне бәяләү.<br>Коммуникатив УУЭ:әңгәмә кора белү, икенче кешенең фикерен тыңлап аңлый белү, үз фикереңне кешегә җиткерә алу осталыгы булдыру.<br>Танып белү: сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;<br>төрмыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булдыру<br>Шәхескә юнәлтелгәнУУЭ:рухи кыйммәтләрне билгеләү, укучыны уратып алган мөхитнең төрле өлкәләренә карата мөнәсәбәт формалаштыру |
| 2 | Фонетика | 10 | *Танып-белү нәтиҗәләре:*<br>– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;<br>– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;<br>– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;<br>-төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;<br>– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.<br>*Регулятив нәтиҗәләр*:<br>– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;<br>– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;<br>– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;<br>– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;<br>– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | – ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;<br>– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;<br>– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.<br>*Коммуникатив* нәтиҗәләр:<br>– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;<br>– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;<br>– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);<br>– парларда һәм күмәк эшли белү;<br>– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;<br>– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү |
| 3 | Лексикология | 5 | *Регулятив нәтиҗәләр*:<br>– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;<br>– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;<br>– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;<br>– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;<br>– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;<br>– ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;<br>– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;<br>– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.<br>*Коммуникатив* нәтиҗәләр:<br>– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;<br>– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;<br>– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);<br>– парларда һәм күмәк эшли белү;<br>– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Танып белү: төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;<br>- кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>- сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;<br>- тәрҗемә итү күнекмәсе.<br>Шәхескә юнәлтелгәнУУЭ:рухи кыйммәтләрне билгеләү, укучыны уратып алган мөхитнең төрле өлкәләренә карата мөнәсәбәт формалаштыру. |
| 4 | Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы | 7 | Регулятив УУЭ: план буенча эшләргә өйрәнү, үз эшмәкәрлегеңне дәреснең максаты белән чагыштыра белү, үз-үзеңне бәяләү.<br>Коммуникатив УУЭ:әңгәмә кора белү, икенче кешенең фикерен тыңлап аңлый белү, үз фикереңне кешегә җиткерә алу осталыгы булдыру.<br>Танып белү: татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;<br>сүзләрне төзелеше һәм ясалышыбуенча тикшерә белү;<br>текст төзелешен һәм тел үзенчәлекләрен билгели белү.<br>Шәхескә юнәлтелгәнУУЭ:рухи кыйммәтләрне билгеләү, укучыны уратып алган мөхитнең төрле өлкәләренә карата мөнәсәбәт формалаштыру. |
| 5 | Әдәби әсәрләр өйрәнү | 9 | Регулятив УУЭ: план буенча эшләргә өйрәнү, үз эшмәкәрлегеңне дәреснең максаты белән чагыштыра белү, үз-үзеңне бәяләү.<br>Коммуникатив УУЭ:әңгәмә кора белү, икенче кешенең фикерен тыңлап аңлый белү, үз фикереңне кешегә җиткерә алу осталыгы булдыру.<br>Танып белү: Дәреслек белән эш итә белү.<br>Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү<br>Төрле текстлар белән эш итү.<br>Белемнәрне системалаштыру өчен таблица, график, схемалар дан файдалану.<br>Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку.<br>Шәхескә юнәлтелгәнУУЭ:рухи кыйммәтләрне билгеләү, укучыны уратып алган мөхитнең төрле өлкәләренә карата мөнәсәбәт формалаштыру. |
| 6 | Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 2 | Регулятив УУЭ: план буенча эшләргә өйрәнү, үз эшмәкәрлегеңне дәреснең максаты белән чагыштыра белү, үз-үзеңне бәяләү.<br>Коммуникатив УУЭ:әңгәмә кора белү, икенче кешенең фикерен тыңлап аңлый белү, үз фикереңне кешегә җиткерә алу осталыгы булдыру.<br>Шәхескә юнәлтелгәнУУЭ:рухи кыйммәтләрне билгеләү, укучыны уратып алган мөхитнең төрле өлкәләренә карата мөнәсәбәт формалаштыру |

# Укыту предметының темаларга якынча бүленеше

| № | Сәгать саны | Бүлекләр һәм темалар | Үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Контроль эш төре | Өй эше | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | План буенча | Фактик | |
| 1 | 1 | Башлангыч сыйныфларда алган белемнәрне кабатлау | - кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>- сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;<br>- тәрҗемә итү күнекмәсе. | Тест биремнәре | 4 нче бит, сөйләргә | 1.09. | | |
| 2 | 1 | Фонетика һәм орфография турында гомуми төшенчә. Авазларның ясалу урыннары. | Фонетика һәм орфография бүлекләренең тел белемендә нинди урын алып торганын билгеләү. | Авазларның ничек ясалганын аңлау | 33 нче күнегү | 08.09 | | |
| 3 | 1 | Сузык авазлар | Татар теленең үзенчәлекле авазларын һәм хәрефләрен әйтергә һәм язарга өйрәнү | авазларны һәм хәрефләрнен дөрес әйтергә һәм язарга өйрәнү | Таблица ятларга | 15.09 | | |
| 4 | 1 | Сузыклар һәм ирен гармониясе | Сүзләрнең сингармонизм законына буйсыну-буйсынмавы. | Сүзлек диктанты | Выучить правила | 22.09. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | [о] һәм [ө] сузыкларының дөрес әйтелешу һәм язылышы<br>Татар теленең үзенчәлекле авазларын һәм хәрефләрен әйтергә һәм язарга өйрәнү | | | | | |
| 5 | 1 | Тартык авазлар | Татар теленең үзенчәлекле авазларын һәм хәрефләрен әйтергә һәм язарга өйрәнү | авазларны һәм хәрефләрнен дөрес әйтергә һәм язарга өйрәнү | Таблица ятларга | 29.09. | | |
| 6 | 1 | [w] һәм [в] тартыклары<br>[h] һәм [х] тартыклары | [w] һәм [в], т[h] һәм [х] артыкларының ясалышлары ягыннан аерылулары | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | 76 нчы күнегү, күчереп язарга, [w] һәм [в] тарт. характеристика бирергә | 06.10. | | |
| 7 | 1 | [г], [гъ], [к], [къ] тартыклары | [г], [гъ], [к], [къ] авазларының ясалышы. Бу авазлар кергән сүзләрне дөрес уку. [гъ], [къ] авазларының татар теленең үз сүзләрендә генә булуы. [гъ], [къ] –кече тел, [г], [к]- тел арты тартык. | Тест | 89 нчы күнегү, күчереп язарга, [г], [гъ], [к], [къ] тартыкларына характеристика бирергә | 13.10. | | |
| 8 | 1 | [м], [н], [ң] тартыклары<br>[ч], [ц], [щ]тартыклары<br>[ء], (һәмзә) тартыгы | [м], [н], [ң] тартыкларының яңгырау, йомык, борын тартыклары булуы, ясалу урыннарын: [м] –ирен-ирен тартыгы, [н]-тел-теш тартыгы, [ң]-кече тел тартыгы, сүз башында килмәве.<br>Татар телендә [ч]-тел алды тартыгы, [ж]- тартыгының саңгырау пары. Рус телендә [ч] тартыгының [тч]-дип әйтелүе; [ц], [щ]тартыкларының алынма сүзләрдә генә кулланылуы<br>[ء], (һәмзә) тартыгының бугазда тавыш ярыларының йомылуы | | Кагыйдәне ятларга 6 сүзгә морфологик анализ | 20.10. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | һәм кинәт ачылып китүе нәтиҗәсендә барлыкка килүе. | | | | | |
| 9 | 1 | Халык авыз иҗаты. “Зирәк карт” әкияте . | Халык авыз иҗаты турында мәгълүмат бирү. Әкиятнең эчтәлеге белән танышу, рольләп уку, сүзлек эше, сорауларга җавап, укытучы ярдәме белән идеясен билгеләү, андагы образларга характеристика бирү, анализ. | | Укып бетерергә | 27.10. | | |
| 10 | 1 | Габдулла Тукай. “Су анасы”, “Шүрәле” әсәрләрен өйрәнү | Шагыйрьнең тормыш юлы, кыскачы иҗаты белән таныштыру. Рольләп укырга өйрәтү, эчтәлек буенча фикер алышу, сүзлек эше, сорауларга җавап, план төзү. | | “Су анасы”, “Шүрәле” әсәрләрен сәнгатьле укырга. Рәсем төшерегә | 10.11. | | |
| 11 | 1 | Иҗек калыплары<br>Сүз басымы. Интонация | Сузыкка тәмамланган иҗек-ачык иҗек, тартыкка тәмамланган иҗек-ябык иҗек дип аталу.<br>Көчлерәк әйтелгән иҗек – басымлы иҗек. Сүзнең басымын билгеләү. Татар телендә басым. Алынма сүзләрдә басым. Татар телендә искәрмәләр. | Тест (10 мин) | Кагыйдәләрне өйрәнергә. 131 нче күнегү, күчереп язарга,сүзләрнең басымын куярга | 17.11. | | |
| 12 | 1 | Графика һәм орфография | Алфавит. Татар алфавиты: 38 хәреф (12 сузык, 24 тартык, 2 авазсыз хәреф). Татар алфавиты белән рус алфавиты арасындагы аерма. | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Алфавитны ятларга. 145 нче күнегүне тикшерү эше итеп эшләргә әзерләнергә | 24.11. | | |
| 13 | 1 | Сузык аваз хәрефләре | Е, ю, я хәрефләренең кулланунның ике очрагы. О, ө хәрефләренең татар теленең үз сүзләрендә бер иҗектә генә | | 156 нчы күнегү, күчереп язарга. 159 нчы күнегү, күп нокталар | 1.12. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кулланылуы. Кушма һәм алынма сүзләрдә о, ө, э хәрефләре язылышына караган бу кагыйдәләрнең сакланмавы | | урынына тиешле хәрефләрне куеп күчереп язарга | | | |
| 14 | 1 | Тартык аваз хәрефләре. | Тартык аваз хәрефләрен язуда дөрес билгеләү. В хәрефе татар сүзләрендә һәм алынма сүзләрдә куллану. Татар телендә бу хәрефнең ирен-ирен тартыгы [w] авазы белән белдерелүе | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | 162 нче күнегү, 1 шигырь яттан диктант, кагыйдә | 08.12. | | |
| 15 | 1 | [г], [гъ], [к], [къ] авазларының язула белдерелүе<br>Ь, Ъ хәрефләренең дөрес язылышы | [гъ], [къ] тартыкларының калын сүзләрдә әйтелүе, гарәп-фарсы сүзләрендә нечкә сүзләрдә дә килә алуы. Бу авазларның язуда к, г хәрефләре аша белдерелүе. К, г хәрефләрене [гъ], [къ] дип дөрес уку кагыйдәләрен белү. Ь, Ъ хәрефләренең аваз белдермәве, нечкәлек, калынлык, аеру билгесе буларак кулланылулары | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | 168 нче күнегү, күчереп язарга, калын хәреф белән язылган сүзләрне тикшерергә. | 15.12. | | |
| 16 | 1 | Фонетика, графика, орфография курсын гомумиләштереп кабатлау | Татар орфографиясенең кыен очракларын тирәнрәк үзләштерү һәм күнекмәгә әйләндерү | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | Кагыйдәләрне кабатларга.<br>172 нче күнегү, биремнәрне язып эшләргә | 22.12. | | |
| 17 | 1 | Контроль диктант | Татар орфографиясенең кыен очракларын тирәнрәк үзләштерү һәм күнекмәгә әйләндерү | Диктант язу | Кагыйдәләрне кабатларга | 29.12. | | |
| 18 | 1 | Г .Исхакыйның тормыш юлы, иҗаты. “ Кәҗүл читек” хикәясе . | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли | Сүзлек эше, текст белән эш | Читек рәсемен ясарга | 19.01. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. | | | | | |
| 19 | 1 | М.Гафуриның тормыш юлы, иҗаты. “Гөлләр бакчасында” шигыре . | Язучының тормыш юлы иҗатының төп фактларын калдыру.Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. | Сүзлек эше, текст белән эш(пауза, логик басым төшкән сүзләрне билгеләү һ.б.), уку(аның төрләре). | Хезмәт темасына караган мәкальләр язып килергә. | 26.01. | | |
| 20 | 1 | Лексика һәм лексикология турында төшенчә. Сүзнең лексик мәгънәсе. | Билгеле бер телдәге сүзләр һәм әйтелмәләр җыелмасы шул телнең лексикасы дип аталу. Телнең лексикасын өйрәнүче фәннең лексикология дип аталуы. Сүзнең лексик мәгънәсе (сүзнең үзенә генә хас мәгънәсе) | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | 183 нче күнегү, сүзлек белән эшләргә | 02.02. | | |
| 21 | 1 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр | Телнең сүзлек составындагы сүзләрнең бер яки күп мәгънә белдерүе. Күп мәгънәле сүзләрнең берничә мәгънә белдерүе. Күп мәгънәле сүзләр арасында мәгънә уртаклыгы | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Хикәя “Яраткан ел фасылым” язып килергә | 09.02 | | |
| 22 | 1 | Г.Ибраһимов “Яз башы” хикәясе. | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету. Хикәя жанрының үзенчәлеген белү. | Сүзлек эше, уку, хикәя турында төшенчә, сорауларга җавап. Туган як табигатенең матурлыгы, сәнгатьчә хәл ителеше . | Өзек ятлау | 16.02. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 23 | 1 | Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы | Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составының үсеш-үзгәрешләре | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | 191 нче күнегү, укырга, 5 сүз белән җөмлә төзергә | 02.03. | | |
| 24 | 1 | Кулланылыш өлкәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. | Кулланылыш өлкәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы төркемнәре: гомумхалык сүзләре, диалекталь сүзләр, һөнәрчелек сүзләре һәм атамаларны аера белү. | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | 206 нчы күнегү, әдәбият дәрес - н гомумхалык сүзләре кергән 10 җөмлә язып алырга | 09.03. | | |
| 25 | 1 | Фразеологик әйтелмәләр. Лексикография | Үзара тыгыз бәйләнешле берничә сүздән төзелгән, бербөтен мәгънә аңлата торган күчерелмә мәгънәле төзелмәнең фразеологик әйтелмә дип аталуы. Башка телләргә сүзгә-сүз тәрҗемә ителмәве. Сүзлекләр. Сүзлекләр турындагы фәннең лексикография дип аталуы. | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш Сүзлекләр белән эш | 226 нчы күнегү, фразеологизмнарн туры килгән сүзләре белән парлап язарга. 5 фразеологизм язып килергә 236 нчы күнегү, татарча-русча сүзлектән файдаланып , русчага тәрҗемә итәргә. | 16.03.. | | |
| 26 | 1 | А.Алишның тормыш юлы, иҗаты. “Сертотмас үрдәк” әкияте. | Шагыйрьнең тормыш юлы турында белешмә .Сүзлек эше, уку(аның төрләре), аерым өзекләрнең эчтәлеген сөйләү, хайваннарга хас сыйфатларны ачыклау, аерым өзекләрне сәхнәләштерү. Сер саклый белү. зучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст | Тест. (10мин) | Рәсем төшерергә | 23.03. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету | | | | | |
| 27 | 1 | Н.Дәүлинең тормыш юлы. “Бәхет кайда” шигыре. | Язучының тормыш юлы Һәм иҗаты турында белешмә. Сәнгатьле уку, шигырьне анализлау, сурәтләү чараларын табу | Язучының тормы юлы һәм иҗаты төп фактларын и калдыру. Сәнгат уку күнекмәләре камилләштерү.Ш | 165нче бит, шигырь ятларга | 06.04. | | . |
| 28 | 1 | Лексика бүлеген кабатлау һәм ныгыту. | Эш кәгазьләреннән белешмә яза белү | | Гаилә турында белешмә язу | 13.04. | | |
| 29 | 1 | Картина буенча сочинение | Картинаны аңлау өчен махсус лексикадан файдалану | | Дәфтәрләргә язып килергә | 20.04. | | |
| 30 | 1 | Тамыр һәм кушымчалар | Тамыр. Аның сүзнең лексик мәгънәсен белдерүе. Кушымча, аларның үзләре генә кулланылмавы | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | 260 нчы күнегү, җөмләләр төзергә, мәгънәле кисәкләр гә аерырга | 27.04. | | |
| 31 | 1 | Төрле сүз төркемнәрен ясаучы кушымчалар. Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. Бәйләгеч кушымчалар. Модальлек кушымчалары | Тамырдаш сүзләрнең төрле ясагыч кушымчалар ярдәмендә бер үк тамырдан ясалулары. Тамырга башта ясагыч, аннан мөнәсәбәт (бәйләгечләр, модальлекләр) белдерүче кушымчалар ялгану. Сүзләрне һәм җөмләләрне бәйләү өчен хезмәт итә торган кушымча-ның бәйләгеч кушымчалар дип аталу. Чынбарлыкка мөнәсәбәтне белдерүче кушымчаларның модальлек кушымчалары дип аталуы | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | Кагыйдәләрне өйрәнергә | 04.05. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 32 | 1 | Кушымчаларның сүзгә ялгану тәртибе | Тамырга ясагыч кушымча, модальлек кушымчасы, бәйләгеч кушымча ялгану | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | 291 нче күнегү, сүзләргә тиешле кушымчалар ялгап, таблицага язарга | 11.05. | | |
| 33 | 1 | Сүз ясалу ысуллары | Сүзләрнең ясалыш ысуллары дип телнең үз чаралары ярдәмендә яңа сүзләр ясалу юллары, алымнары аталу. Сүз ясалышының сүз ясагыч кушымчалар ялгау, сүзләрне кушу, сүзләрнең аваз составын үзгәртү, сүзләрнең мәгънәсен үзгәртү, сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү, сүзләрне кыскарту ысуллары булуы. Сүзнең | Телдән эш, күнегүләр, таблицалар өстендә язма эш | “Әллүки” журналыннан төрле ысул белән ясалган 10 сүз язып килергә | 18.05. | | |
| 34 | 1 | Контроль диктант | Ел буенча өйрәнелгән кагыйдәләрне ныгыту | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | “Күңелле җәй” дигән темага сочинение язарга | | | |

## Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү

Татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану таләп ителә:

- күрсәтмә әсбаплар;
- белешмә материаллар;
- аудио һәм видео әсбаплар;
- компьютер программалары;
- электрон китапханә;
- татар сайтлары

1.http://www.tugantelem.narod.ru татар телен өйрәнү
2.http://tatar.com.ru/fonetika.php
татар теле фонетикасы
3.http://tatar.moy.su

татар теле турында
4. http://. belem.ru
новости (яңалыклар)
5. http://. suzlek.ru   on- line
русча сүзлек
6. http://. Tugan-tel.at.ru     шрифтлар  һәм IT- технологияләр
7. http://. Kitapxane.at.ru
татар телендәге әдәби әсәрләр
8. http://. Tatar.com.ru
татар телендә сүзлекләр
9. http://. Tatarca.boom.ru    татарча текстлар
10. http://. tataroved.ru
татар тарихы: төрки – татар дөньясы
11.http://vneuroka.ru
мавыктыргыч уеннар
12. http://www.fasi.gov.ru
Фән һәм инновацияләр буенча федераль агентлык


1. Дәреслек: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең ө нче сыйныфы өчен дәреслек
2. Татар теле морфологиясе. Ф.М. Хисамова.- Казан, “Мәгариф”, 2005.
3. Хәзерге татар әдәби теле Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. – Казан, “Мәгариф”, 1994.
4. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттаров.-Казан:”Раннур”, 2000.
5. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова. Казан, “Яңалиф”, 2006.
6. Татар теленнән тестлар. Н.В.Максимов. Казан, “Мәгариф”, 2002, 2008.
7. Изложениеләр җыентыгы. Казан, “Мәгариф”, 2003.
8. V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр. З.Н.Хәбибуллина, М.А. Вәлиуллин, Х.Г.Фәрдиева. Казан, “Мәгариф”, 2003.